Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 5**

Масловка авылы 10.03.2025 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге XIII номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Масловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 октябрендәге XIII номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (26.10.2020ел № IX-I үзгәрешләр кертелгән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.7 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«- торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча муниципаль район, шәһәр округы чикләрендәге җирлек составына керүче торак пункт территориясе өлешендә Татарстан Республикасы Законы нигезендә.».

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Масловка авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Масловка авылы, Центр урамы, 13 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Масловка авыл җирлеге башлыгы А.И.Егоров